**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.08.2023 № 1499

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын эшләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы 24 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү максатларында КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Осинники авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын эшләүгә карешергә.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасарына:

- генераль планны эшләү өчен чыгыш ясаучы мәгълүматларны әзерләүне күрсәтелгән техник (шәһәр төзелеше) биреме нигезендә тәэмин итәргә;

- җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, физик һәм юридик кызыксынучы затлар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм карауны тәэмин итәргә;

- Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24, 25 статьялары таләпләре нигезендә проектны карауны, килештерүне, раслауны башкарырга.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (инфраструктура үсеше, төзекләндерү һәм ТКХ буенча) Р.Р. Баржановка йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин